КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 596

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз нияттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык арасында алкогольле продукциядән, сырадан, тәмәкедән явыз нияттә файдалануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 июнь, 525 нче; 2011 ел, 24 сентябрь, 788 нче; 2013 ел, 27 май, 354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Тәмәке тартуны чикләү турында» 2001 ел, 10 июль, ФЗ-87 нче Федераль законның 4, 6 статьялары» сүзләрен «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке тарту яки никотинлы продукция куллану нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктның икенче абзацында «Тәмәке тартуны чикләү турында» 2001 ел, 10 июль, ФЗ-87 нче Федераль законны» сүзләрен «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке тарту яки никотинлы продукция куллану нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законны» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин